РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018елның 24 апрелендәге 9-31номерлы ТР Буа муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын социаль гарантияләр белән тәэмин итү, тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль Законына, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» Буа муниципаль районы Советының 2018елның 24 апрелендәге 9-31номерлы карарының 1 нче кушымтасын (12.11.2020 ел, № 8-3, 21.10.2022 ел, №4-35, 14.02.2023 ел, №4-40 карары редакциясендә) яңа редакциядә язарга (кушымта).
2. «Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» Буа муниципаль районы Советының 2018елның 24 апрелендәге 9-31номерлы карарының 5 нче кушымтасын (12.11.2020 ел, № 8-3, 21.10.2022 ел, №4-35, 14.02.2023 ел, №4-40 карары редакциясендә) яңа редакциядә язарга (кушымта).
3. Буа муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә карата яллаучы (эш бирүче) вәкиле вәкаләтләре җирле үзидарәнең тиешле органы җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.
4. Буа муниципаль районы территориясендәге җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә:

алар чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерергә;

муниципаль район башлыгы белән килешү буенча муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмәүче һәм әлеге органнарны техник тәэмин итү буенча вазыйфаларны башкаручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү мәсьәләләрен үз хокукый актлары белән бертөрле җайга салырга.

5. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов

Буа муниципаль районы Советының
2018 елның 24 апрелендәге
9-31номерлы карарына
1 нче кушымта

(Буа муниципаль районы Советының 12.11.2020 ел,
№ 8-3, 21.10.2022 ел, № 4-35, 14.02.2023 ел,
№4-40 карарлары редакциясендә)

**Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хезмәт хакы**

| № т/б | Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи хезмәт хакы, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Башкарма комитет җитәкчесе | 36506 |
| 2 | Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 33175 |
| 3 | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 32908 |
| 4 | Вәкиллек органы аппараты җитәкчесе | 33175 |
| 5 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 32775 |
| 6 | Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 29977 |
| 7 | Башкарма комитетның эшләр идарәчесе | 30777 |
| 8 | Башкарма комитет аппараты идарәсе башлыгы | 25314 |
| 9 | Бүлек башлыгы(мөдире) | 24248 |
| 10 | Башкарма комитет идарәсе составында бүлек башлыгы | 24248 |
| 11 | Башкарма комитет аппараты идарәсе  башлыгы урынбасары | 23982 |
| 12 | Башкарма комитетның бүлек башлыгы урынбасары, башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 21184 |
| 13 | Муниципаль район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе | 21184 |
| 14 | Баш белгеч | 19452 |
| 15 | Әйдәп баручы белгеч | 18253 |
| 16 | 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч | 17054 |

Буа муниципаль районы Советының
2018 елның 24 апрелендәге
9-31номерлы карарына
5 нче кушымта

(Буа муниципаль районы Советының 12.11.2020 ел,
№ 8-3, 21.10.2022 ел, № 4-35, 14.02.2023 ел,
№4-40 карарлары редакциясендә)

**Айлык акчалата бүләкләү күләме һәм түләү тәртибе**

1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи хезмәт хакының 41 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә.